**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№886**
**10.02.2021**

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 5 ноябрендәге 999 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 27 сентябрендәге 5863 номерлы карары (Башкарма комитетның 2014 елның 17 февралендәге 944 номерлы, 2015 елның 18 ноябрендәге 6571 номерлы, 2016 елның 29 апрелендәге 2159 номерлы, 2017 елның 6 апрелендәге 1955 номерлы, 2018 елның 7 мартындагы 1180 номерлы, 2019 елның 22 октябрендәге 5404 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган муниципаль белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларында балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме, аны билгеләү турында гариза бирү ае алдыннан килгән алты календарь айдан алдагы 12 календарь ай өчен гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.»;

2) 7.1 пунктка түбәндәге эчтәлектә 18 пункт өстәргә:

«18) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлары булмау турында белешмә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар, 2021 елның 1 апрелендә үз көченә керә торган 1 пунктның 1 пунктчасыннан тыш, басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов